**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**БИЕКТАУСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
Х.Фатхутдинова ул., д.10,
с. Биектау, 422665

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИЕКТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Х. Фатхутдинова урамы, 10 нчы йорт,
Биектау, 422665

Тел.: (884361)32-5-26, факс: 32-5-26. E-mail:biek.rs@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 **елның 14 августы** **Биектау ав** **№ 40**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең 2017 елның 16 ноябрендәге 24 номерлы карары белән расланган 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга яраклаштыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, шәһәр округларының социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турында» 2015 елның 1 октябрендәге 1050 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, карар бирәм::

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 16 ноябрендәге 24 номерлы карары белән расланган 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына (2018 елның 24 мартындагы 12 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

программа паспортында:

1.1) 7 юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле 8 юл өстәргә: «халыкны социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин итүнең максатчан күрсәткечләре (Индикаторлары)»:

| | |
|---|---|
| "Социаль инфраструктура объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү | 1. Биектау торак пунктында административ бина төзелеше;<br>2. Биектау торак пунктында 200 урынга исәпләнгән модульле клуб төзелеше;<br>3. Биектау авылында модульле балалар бакчасы |

| | |
|---|---|
| буенча планлаштырылган чараларның (инвестицион проектларның) киңәйтелгән тасвирламасы | төзелеше;<br>4. Биектау т. п. урам тренажерлары урнаштыру;<br>5. Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын капиталь ремонтлау һәм ремонтлау;<br>6. Авыл җирлеге торак пунктларының урам-юл челтәрен капиталь ремонтлау һәм ремонтлау;<br>7. Су белән тәэмин итү объектларын төзү һәм реконструкцияләү; 8. Чаллы-Баш " торак пунктында авыл клубын капиталь ремонтлау. |

1.2) 8-10 юлларны 9-11 юллар белән санарга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Биектау авылы, Х.Сафиуллин урамы, 4 йорт; Околоток-Янасала авылы, Калинин урамы, 102 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге Башлыгы К.Х.Галимуллин